# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Пеләмеш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**19.11.2020** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Пеләмеш торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2020 елның 19 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Пеләмеш пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм irектән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Пеләмеш торак пунктында спорт мәйданчыгы сатып алу, урнаштыру.

2. Пеләмеш торак пунктында урамнарны яктырту өчен яктылык диодлы лампалары сатып алу, аларны урнаштыру, шартнамә буенча эшләр өчен түләү;

3. Пеләмеш торак пунктында халыкны су белән тәэмин итү (ремонт, хезмәт күрсәтү, тирәнлек насослары һәм төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
4. Пеләмеш торак пунктында юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү;
5. Янгын автомашинасын карап тоту, ремонтлау, янгын сүндерү машинасын йөртүчегә килешү буенча түләү
6. Пеләмеш торак пунктында Пеләмеш елгасы аша күперне ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу һәм ремонт өчен хезмәт шартнамәсе буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 258 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 150 кеше, бу 58 % тәшкил итә.